**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 июнь № 367

г. Казань

2016 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру буенча чаралар турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2016 ел, 17 март, 147 нче карарын тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны бергә финанслауга Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны файдалану тәртибе;

2016 елда Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында эштән чыгару куркынычы булган оешмалар хезмәткәрләрен, шулай ук ябылу яисә хезмәткәрләр саны яки штаты кыскару белән бәйле бүтән оешмалардан эштән чыгарылып даими эшкә кабул ителгән хезмәткәрләрне алга китеп һөнәри укыту яки стажировка оештыруга (шул исәптән башка җирлектә) субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру белән бәйле чыгымнарын каплауга, инфраструктура булдыру, эш урынына яраклашу һәм остазлыкны да кертеп, субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда эш бирүчеләргә һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшкә алынган гражданнарның хезмәте өчен түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе;

2016 елда эш бирүчеләргә эштән чыгарылу куркынычы булган оешмалар хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә алынган гражданнарның хезмәте өчен түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибе.

2. Әлеге карар белән расланган субсидияләр бирү тәртибен куллану буенча аңлатулар Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалаткан дип танырга:

«Эш бирүчегә оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләре арасыннан вакытлыча эшкә урнаштырылган гражданнарның һәм эш эзләүче гражданнарның хезмәт өчен түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 219 нчы;

«Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны алдан һөнәргә өйрәтүне һәм аларның стажировкасын оештыруга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 220 нче.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков